ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                КАРАР

_______________ с. Верхний Услон _______________

Җирлекнең генераль планыннан өземтә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

Физик һәм юридик затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү буенча Югары Ослан муниципаль районы хакимияте муниципаль органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген һәм сыйфатын күтәрү максатларында һәм Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Тәмамланмаган төзелеш объектының техник планы формасын һәм аны әзерләүгә таләпләрне раслау турында»10.02.2012 ел, №52 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Уставы белән Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Җирлекнең генераль планыннан өземтә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын расларга.
2. Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге начальнигына әлеге карар белән расланган муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын үтәүне тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Социаль-икътисадый үсеш буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасарына йөкләргә .

Башкарма комитет җитәкчесе                Л.С. Хәкимҗанов

Әзерләде һәм бастырды:
А.Д.Сагдеева
2 экз.